**ГЛАВА**
**АМЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Әмзә ав. **КАРАР**

«04» октябрь 2022 ел № 11

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Нурлат муниципаль районының Яңа Әмзә авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 16 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Яңа Әмзә авылы, Ленин урамы, 12нче йорт адресы буенча урнашкан Яңа Әмзә авылы мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Яңа Әмзә авылында яшәүче барлык гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.
2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Әмзә авылында яшәүче гражданнар өчен Әмзә авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Элек расланган гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләгә үзгәрешләр кертүгә сез ризамы?:
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының торак пунктындагы Яңа Әмзә авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 2021 елның 3 декабрендәге 5 номерлы карарга
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Яңа Әмзә авылында Халык җыенының 2021 елның 3 декабрендәге 6 номерлы карарына, аны киләсе редакциядә раслап:

«2022 елда Нурлат муниципаль районының Яңа Әмзә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме:

- янгын сүндерү җиһазларын сатып алу
- янгын сүндерү техникасын урнаштыру өчен торак булмаган бина (гараж) сатып алу
- янгын сүндерү техникасын урнаштыру өчен торак булмаган бинаны капиталь ремонтлау;

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Әмзә авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге башлыгы А.Ф.Сафиуллина